КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1336

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә, шәһәр һәм (яки) шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, метрополитен белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләрнең алып бетерелмәгән керемнәрен каплау өлешендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен 2021 елда Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә, шәһәр һәм (яки) шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, метрополитен белән пассажирлар

йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләрнең алып бетерелмәгән керемнәрен каплау өлешендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен 2021 елда Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 декабрь, 1336 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә, шәһәр һәм (яки) шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, метрополитен белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләрнең алып бетерелмәгән керемнәрен каплау өлешендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен 2021 елда Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә, шәһәр һәм (яки) шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, метрополитен белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләрнең алып бетерелмәгән керемнәрен каплау өлешендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен 2021 елда Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары) (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба шул ук эзлеклелектә – пассажир йөртүчеләр, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Башка бюджетара трансфертлар бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә, пассажир йөртүчеләрнең чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый акт булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының

җыелма бюджет исемлегендә) финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре аларны үтәү өчен җитәрлек күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен кертеп) булу;

муниципаль берәмлектәге вәкаләтле җирле үзидарә органының транспортта йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторы (алга таба – t операторы) белән муниципаль берәмлектә шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләренә һәм шәһәр яны элемтәсенең автомобиль транспортына транспортта йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасын кертү һәм аңа хезмәт күрсәтү буенча үзара хезмәттәшлеген раслый торган документ булу;

Министрлык белән муниципаль берәмлектәге вәкаләтле җирле үзидарә органы арасында финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлек йөкләмәсе күздә тотыла торган башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү һәм килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

5. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертлар бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

6. Башка бюджетара трансфертларны файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткече) – 2021 елда i муниципаль берәмлегендә транспортның j төре белән (j –транспорт төрләре (автобус, троллейбус, трамвай, метрополитен)) пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт белән хезмәт күрсәтүнең «даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты» күрсәткече ярдәмендә билгеләнә торган, зурлыгы ≥ 0,7 тиеш булган ышанычлыгы.

2021 елга i муниципаль берәмлегендә транспортның j төре белән даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары расписаниеләрен үтәү коэффициенты ($К_{распj)}$ түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К_{распj} = \frac{Q_{фактрейсj}}{Q_{рейсраспj}} \geq 0,7,$$

монда:

$Q_{фактрейсj}$ – 2021 елга i муниципаль берәмлегендә транспортның j төре белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда башкарылган рейсларның факттагы саны;

$Q_{фактрейсj}$ – 2021 елга i муниципаль берәмлегендә транспортның j төре белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда расписаниедә билгеләнгән рейслар саны;

7. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлектәге вәкаләтле җирле үзидарә органы Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗның финанс-икътисадый нигезләве теркәлгән, ирекле формада язылган башка бюджетара трансферт бирү турында заявка (алга таба – заявка);

муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы карарыннан Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә пассажир йөртүчеләрнең чыгымнарын каплауга муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен муниципаль берәмлек бюджетында бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлеге) турында өземтә;

түбәндәгеләрне раслый торган документларның күчермәсен:

2021 елның сентябренә – октябренә пассажир йөртүчеләрнең транспортта йөрү өчен түләү төрләре буенча (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар, транспорт кушымтасы булган электрон карталар, банк карталары, кәгазь акча белән исәп-хисап ясау) муниципаль берәмлектә шәһәр элемтәсендәге муниципаль маршрутларда j транспорт төрендә һәм шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында бер тәүлеккә уртача табышы;

2021 елның 22 ноябреннән 31 декабренә кадәр (алга таба – хисап чоры) пассажир йөртүчеләрнең транспортта йөрү өчен түләү төрләре буенча (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар, транспорт кушымтасы булган электрон карталар, банк карталары, кәгазь акча белән исәп-хисап ясау) муниципаль берәмлектә шәһәр элемтәсендәге муниципаль маршрутларда j транспорт төрендә һәм шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында табыш күләме;

билетларны автовокзалларда (автостанцияләрдә) реализацияләүгә бәйле рәвештә, пассажир йөртүчеләрнең 2021 елның сентябре – октябренә муниципаль берәмлектә шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында бер тәүлеккә уртача табышы һәм пассажир йөртүчеләрнең хисап чорына табышы күләмен раслый торган билетларны исәпкә алу документлары күчермәсе;

бу Тәртипнең 4 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль хокукый акт күчермәсен.

8. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында яки башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының үтәлмәве;

бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

бу Тәртипнең 7 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

10. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлеккә заявка теркәлгән көннән соң эш

көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә җибәрелә.

11. Муниципаль район бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

12. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Министрлык белән муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы арасында Министрлык тарафыннан раслана торган форма буенча төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

13. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең зурлыгы;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

муниципаль берәмлек бюджетының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелгән мәгънәсе турында хисаплар бирү сроклары һәм формалары;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең билгеләнгән мәгнәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлектәге вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан Килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләре үтәлүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

14. i муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме ($N_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$N_i = SUM\ N_{iv},$$

монда:

$N_{iv}$ – транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча (v – транспортта йөрү өчен түләү төрләре (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар, транспорт кушымтасы булган электрон карталар, банк карталары, кәгазь акча белән исәп-хисап ясау)) i муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме.

Транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча i муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме ($N_{iv}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$N_{iv} = SUM\ (N_{vгорij} + N_{vпрi} + N_{АВпрi}),$$

монда:

$N_{vгорij}$ – транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча шәһәр элемтәсендә муниципаль маршрутларда транспортның j төрендә i муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме;

$N_{vпрi}$ – транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында i муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме;

$N_{АВпрi}$ – автовокзаллар (автостанцияләр) кассаларында билетларны реализацияләгәндә шәһәр элемтәсендә муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында i муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме;

Транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча шәһәр элемтәсендә муниципаль маршрутларда транспортның j төрендә i муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме ($N_{vгорij}$ ) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$N_{vгорij} = SUM ((Урт_{(тәүл.табыш)vгорijt} \times K_{көн}) – Факт_{(табыш)vгорijt}),$$

монда:

$Урт_{(тәүл.табыш)vгорijt}$ – t операторы мәгълүматлары буенча транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча i муниипаль берәмлегендәге шәһәр элемтәсендә муниципаль маршрутларда транспортның j төрендә пассажир йөртүчеләрнең 2021 елның сентябре – октябренә бер тәүлеккә уртача табышы;

$Факт_{(табыш)vгорijt}$ – t операторы мәгълүматлары буенча транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча i муниипаль берәмлегендәге шәһәр элемтәсендә муниципаль маршрутларда транспортның j төрендә пассажир йөртүчеләрнең хисап чорына табышы;

$K_{көн}$ – хисап чорында көннәр саны.

Транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутларда транспортның j төрендә i муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме ($N_{vпрi}$ ) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$N_{vпрi} = SUM ((Урт_{(тәүл.табыш)vпрit} \times K_{көн}) – Факт_{(табыш)vпрit}),$$

монда:

$Урт_{(тәүл.табыш)vпрit}$ – t операторы мәгълүматлары буенча транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча i муниипаль берәмлегендәге шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында пассажир йөртүчеләрнең 2021 елның сентябре – октябренә бер тәүлеккә уртача табышы;

$Факт_{(табыш)vпрit}$ – t операторы мәгълүматлары буенча транспортта йөрү өчен v түләү төре буенча i муниипаль берәмлегендәге шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында пассажир йөртүчеләрнең хисап чорына табышы;

$K_{көн}$ – хисап чорында көннәр саны.

Автовокзаллар (автостанцияләр) кассаларында билетларны реализацияләгәндә шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутларда i муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме ($N_{АВпрi}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$N_{\text{АВпрi}} = (\text{Урт}_{(\text{тәүл.табыш АВ})\text{прit}} \times \text{К}_{\text{көн}}) - \text{Факт}_{(\text{табышАВ})\text{прit}}),$$

монда:

$\text{Урт}_{(\text{тәүл.табыш АВ})\text{прit}}$ – автовокзаллар (автостанцияләр) кассаларында билетларны реализацияләүгә бәйле рәвештә, i мунииипаль берәмлегендәге шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында пассажир йөртүчеләрнең 2021 елның сентябре – октябренә бер тәүлеккә уртача табышы;

$\text{Урт}_{(\text{тәүл.табыш АВ})\text{прit}}$ – автовокзаллар (автостанцияләр) кассаларында билетларны реализацияләүгә бәйле рәвештә, i мунииипаль берәмлегендәге шәһәр яны элемтәсендә муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында пассажир йөртүчеләрнең факттагы табышы;

$\text{К}_{\text{көн}}$ – хисап чорында көннәр саны.

15. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына күчерелә.

16. Муниципаль берәмлектәге вәкаләтле җирле үзидарә органы 2022 елның 1 февраленә кадәр килешүдә каралган тәртиптә һәм форма буенча муниципаль район бюджетының финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелгән зурлыгы турында Министрлыкка хисаплар тапшыра.

17. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткече зурлыгын 2021 ел йомгаклары буенча фактта ирешелгән нәтиҗәлелек күрсәткече зурлыгы белән чагыштыру аша гамәлгә ашырыла.

18. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы бу Тәртипнең 16 пункты нигезендә тапшырыла торган хисапларның дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

19. 2022 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2022 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

20. 2022 елның 1 гыйнвары хәленә карата муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына 2022 елның 1 апреленә кадәр тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

21. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

22. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган, шул исәптән бу Тәртипнең 19 һәм 20 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

23. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.